РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2025 Кукмара ш. № 662

«Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә бердәм айлык социаль йөртү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль йөртү билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 11 февралендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. «Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә бердәм айлык социаль йөртү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль йөртү билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге

бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 11 февралендәге 155 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада: «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Кушымтаның 6 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) субсидия алучыга һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булып торучы затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү максатларында, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә Кукмара муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне башкаруга ризалык бирә.»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Вәкаләтле орган субсидияләр алучыларга һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булып торучы затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү максатларында, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә Кукмара муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан мәҗбүри тикшерү үткәрә.»;

Гражданнарның аерым категорияләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә бердәм айлык социаль йөртү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль йөртү билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым

категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатларында «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымтаның 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Әлеге Килешү белән Субсидия алучы субсидия алучыга һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булып торучы затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү максатларында, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә Кукмара муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне башкаруга ризалык белдерә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**